# 2022 елның 1 кварталында Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләү турында мәгълүмат

2022 елның 1 кварталында Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында гражданнардан язмача кергән һәм шәхси кабул итүдә алынган **1970** мөрәҗәгать карап тикшерелде (2021 елда – 2152).

Мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан:

**1305** – язмача мөрәҗәгатьләр (2021 – 1365).

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе адресына 858 гариза бирүчедән 38 коллектив мөрәҗәгать керде (2021 елда – 1045 гариза бирүчедән 52 коллектив мөрәҗәгать).

1305 мөрәҗәгатьнең 252 се уңай хәл ителде, бу гомуми санның 19,3 % ын тәшкил итә, 43 мөрәҗәгать ведомство буйсынуындагы оешмаларга адресланды, калганнары буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үз социаль хәлен күрсәткән гражданнар түбәндәге категорияләргә бүленә:

- эшләүчеләр: 80 (6,13 %);
- пенсионерлар: 65 (4,98 %);
- эшсезләр: 23 (1,76 %);
- интеллигенция: 22 (1,69 %);
- хезмәткәрләр: 15 (1,15 %);
- эшмәкәрләр: 13 (0,99 %);
- хуҗабикәләр: 5 (0,38 %);
- укучылар: 1 (0,08 %);
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: 1081 (82,84 %).

Льготалы категориягә ия булуларын күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр арасында күпчелекне инвалидлар – 64 (4,9 %), күп балалы гаиләләр – 27 (2,07 %), ялгыз ата-аналар – 2 (0,15 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – 1 (0,08 %), качаклар – 1 (0,08 %) кешене тәшкил итте.

Гражданнардан кергән язмача мөрәҗәгатьләрне анализлаудан күренгәнчә, 2022 елның 1 кварталында шәһәрдәшләр өчен түбәндәге мәсьәләләр иң актуаль булып саналган:

- торак-коммуналь хуҗалыгы – 523 (2021 – 479);

- юл хуҗалыгы – 151 (2021 – 184);

- җирдән файдалану – 93 (2021 – 73);

- төзелеш – 82 (2021 – 92);

- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – 69 (2021 – 27);

- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия бирү – 66 (2021 – 114);

- торак өлкәсе – 63 (2021 – 101);

- транспорт хезмәте күрсәтү – 51 (2021 – 61);

- сәламәтлек саклау – 47 (2021 – 33);

- социаль тәэмин итү – 32 (2021 – 57);

- законлылык һәм хокук тәртибен тәэмин итү – 33 (2021 – 31);

- элемтә мәсьәләләре –23 (2021 – 20);

- финанс өлкәсе – 20 (2021 – 23);

- хезмәт һәм мәшгульлек – 18 (2021 – 20);

- башкалар – 35 (2021 – 50).

**665** чаллылы шәхси кабул итү вакытында кабул ителде (2021 – 787). 271 мөрәҗәгать буенча кирәкле чаралар күрелде, мөрәҗәгать иткән 371 гражданга аңлатмалар бирелде, 23 мөрәҗәгать контрольдә тора.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры 46 чаллылы кабул ителде.

Җирле үзидарә органнарында гражданнарның бер генә мөрәҗәгате дә игътибарсыз калмый.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы көн саен үткәрелә, аларны үз вакытында карап тикшерү контрольдә тотыла, башкару дисциплинасына анализ ясала.

Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Һәр мөрәҗәгать итүчегә гамәлдәге законнарга нигезләнгән язмача җаваплар һәм аңлатмалар бирелә.